БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 апрель 2019 ел № 183

**«Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең Нигезләмәсен яңа редакциядә раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясенең мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең Нигезләмәсен яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Зәкиева Алия Юныс кызына әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәне Татарстан Республикасы Федераль налог хезмәтенең 18 номерлы районара налог инспекциясендә теркәү өчен гариза язу, юридик затларның бердәм дәүләт реестрына башка төрле үзгәрешләр кертү, шул максатларда гаризалар һәм башка документлар имзалау, кануннар нигезендә билгеләнгән тәртипләр һәм вакыт кысаларында башка гамәлләр башкару вәкаләтләре бирергә.

3. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2014 елның 8 августындагы «Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең Нигезләмәсен яңа редакциядә раслау турында» 238 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин